СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.10.2022 г.Зеленодольск № 219

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гражданнар өчен сораштыру үткәрүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 31 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле үзидарә органнары һәм Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан карарлар кабул иткәндә халыкның фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гражданнар өчен сораштыру үткәрүне билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне, кушымтада каралганча расларга.
2. «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының муниципаль берәмлегендә гражданнар өчен сораштыруны билгеләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 15 декабрендәге 133 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Совет рәисе** **М.П.Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2022
елның 28 октябрендәге 219
номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы
территориясендә гражданнар өчен сораштыруны билгеләү һәм
уздыру тәртибе турындагы
нигезләмә

**1. Гомуми нигезләмәләр**

1.1. Гражданнарны сораштыру (алга таба-сораштыру) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы халкының турыдан-туры ихтыяр белдерүенең бер формасы булып тора.

1.2. Гражданнарны сораштыру Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының бөтен территориясендә (алга таба - Районның) яисә аның территориясенең бер өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча фикерләрен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә исәпкә алу өчен үткәрелә.

1.3. Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим итү характерына ия.

**2. Сораштыруны үткәрү принциплары**

2.1. Гражданнар сораштыруында сайлау хокукына ия һәм сораштыру үткәрелә торган территория чикләрендә яшәүче район халкы катнашырга хокуклы.

Гражданнарның инициатив проектка ярдәм итү турындагы фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча инициатив проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган сораштыруда уналты яшькә җиткән район халкы яисә аның өлеше вәкилләре катнашырга хокуклы.

2.2. Район халкы тигез принципларда сораштыруда катнаша. Сораштыруда катнашучы һәр кеше бер тавышка ия һәм сораштыруда турыдан-туры катнаша.

2.3. Сораштыруда гражданнарның җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазифаи хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, җәмәгать берләшмәләренә карауларына бәйле рәвештә нинди дә булса турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган чикләүләр рөхсәт ителми.

2.4. Гражданнар сораштыруда ирекле рәвештә һәм үз теләге белән катнаша. Сораштыру барышында берәү дә үз фикерләрен һәм карашларын белдерүгә яисә алардан баш тартуга мәҗбүр ителә алмый.

2.5. Сораштыру нәтиҗәләрен әзерләү, үткәрү һәм билгеләү законлылык, ачыклык һәм хәбәрдарлык принциплары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.6. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары халыкка сораштыруда катнашу хокукын гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә тиеш.

## 3. Сораштыру төрләре

3.1. Сораштыру яшерен, ачык тавыш бирү юлы белән үткәрелә.

Гражданнардан сораштыру үткәрү өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (алга таба - рәсми сайт) файдаланылырга мөмкин.

3.2. Яшерен тавыш бирү сораштыру кәгазьләре буенча үткәрелә.

3.3. Ачык тавыш бирү гражданнар җыелышларында үткәрелә.

## 4. Сораштыруны билгеләү тәртибе

4.1. Район гражданнарыннан сораштыру түбәндәге инициатива белән үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы (алга таба - Район Советы) яисә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы (алга таба – Район Башлыгы) - җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;

- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары - төбәк һәм төбәкара әһәмияттәге объектлар өчен муниципаль берәмлек җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнарның фикерен исәпкә алу өчен;

- инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган районда яки аның өлешендә уналты яшькә җиткән яшәүчеләр - гражданнарның әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерләрен ачыклау өчен;

4.2. Район Башлыгына караган сораштыру уздыру инициативасы, әлеге орган тарафыннан сораштыруны билгеләү турында тиешле карар кабул итүдә чагыла.

Район Башлыгына караган сораштыру уздыру инициативасы Районыбыз Советына сораштыру уздыру турындагы үтенечнамәне юллауда чагыла.

Район халкына караган сораштыру уздыру инициативасы инициатив төркем тарафыннан Район Советына сораштыру уздыру турында үтенечнамәне юллауда чагыла;

4.3. Сораштыру үткәрү турындагы үтенечнамәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- сораштыру үткәрүнең мотивлары;

сораштыруга чыгарылган сорауның (сорауларның )тәкъдим ителә торган формулировкалары;

- сораштыру территориясе;

- Сораштыруны үткәрүнең фаразланган датасы һәм аның төре.

4.4. Гражданнарны сораштыру билгеләү турындагы карары Район Советы тарафыннан кабул ителә.

4.5. Сораштыруны билгеләү турындагы карар сораштыру үткәрү турында үтенечнамә алган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча һәм аны үткәрүгә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.

Сораштыру инициаторы белән сораштыруга чыгарылган сорауның (сорауларның ) тәкъдим ителә торган формулировкалары сораштыруны билгеләү турында карар кабул итү алдыннан Район Советы белән килештерү (аныклау) булырга мөмкин

4.6. Сораштыруга чыгарылган сорауның (сорауларның ) тәкъдим ителә торган формулировкалары гамәлдәге законнарга, әлеге Нигезләмәгә каршы килсә, Район Советы инициаторга сораштыру үткәрүдә баш тартырга хокуклы.

4.7. Район Советының гражданнар арасында сораштыру билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр билгеләнә:

- сораштыру уздыру датасы һәм сроклары;
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы;
- сораштыру үткәрү методикасы;
- сораштыру кәгазенең формасы;
- сораштыруда катнашучы район халкының минималь саны;
- гражданнар арасында рәсми сайттан файдаланып сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе.

4.8. Сораштыруны билгеләү карары, аны үткәргәнче 10 көннән дә соңга калмыйча, мәҗбүри басылып чыгарга тиеш

4.9. Сораштыруда чыгарыла торган сораулар Россия Федерациясе законнарына һәм Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль район» муниципаль берәмлегенең Уставына (алга таба - Устав) каршы килмәскә тиеш.

4.10. Сораштыруга китерелгән сораулар, аларны озак итеп аңлатып тормас өчен, аңлаешлы формалаштырылырга тиеш.

## 5. Сораштыру үткәрү комиссиясе

5.1. Гражданнардан сораштыру үткәрүне Сораштыру комиссиясе (алга таба - Комиссия) әзерли һәм уздыра.

5.2. Комиссия Район Советы тарафыннан 5 кеше күләмендә билгеләнә.

5.3. Комиссия составына мәҗбүри тәртиптә Район Советы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты вәкилләре, шулай ук сораштыру үткәрелә торган территория җәмәгатьчелеге вәкилләре керә.

5.4. Комиссия аны төзү турында карар кабул ителгәннән соң, өченче көннән дә соңга калмыйча, чакырыла. Беренче утырышта Комиссия сораштыру участокларын раслый, шулай ук, сораштыру үткәрү пунктларында уздырылган очракта, мондый пунктларның санын һәм урнашу урынын раслый.

Комиссия утырышлары кирәк саен аның рәисе тарафыннан чакырыла. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санының яртысыннан ким булмаган өлеше катнашса, тулы хокуклы дип санала.

Комиссия карарлары утырышта катнашкан комиссия әгъзаларыннан гади күпчелек тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Комиссия, гражданнардан сорашып белешү уздыру өчен, кирәкле санда эшче төркемнәр булдырырга хокуклы.

5.5. Сораштыру участоклары, Комиссиянең урнашу урыны һәм гражданнарның сораштыру үткәрү пунктларының урнашу урыннары сораштыру үткәрелгәнче кимендә 10 көн алдан бастырылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

5.6. Сораштыру үткәрү комиссиясе:

- гражданнарны сораштыру үткәргәндә әлеге Нигезләмәнең үтәлешен оештыра;
- сораштыру үткәрү пунктларын җиһазлый;
- сораштыру кәгазьләрен әзерләүне тәэмин итә;
- сораштырганда имзалар җыюны оештыра;
- район халкының сораштыруда катнашуын тәэмин итә;
- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә сораштыруда халыкның тавыш бирүен оештыра;
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, иҗтимагый берләшмәләр, массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек итә;
- гражданнардан сорашып белешү нәтиҗәләрен билгели;
- гражданнардан сорашып белешү үткәрүгә бәйле гаризаларны һәм шикаятьләрне карый;
- гамәлдәге законнар һәм әлеге Нигезләмә нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

5.7. Комиссия вәкаләтләре сораштыру нәтиҗәләрен рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң туктатыла.

## 6. Сораштыру участоклары. Сораштыруда катнашучыларның исемлекләре

6.1. Сораштыру участогы -район территориясендә гражданнарны сораштыру алып барыла торган Сораштыру үткәрү комиссиясе билгеләгән территория.

Сораштыру территориясе бердәм сораштыру участогын тәшкил итә.

Сораштыру участокларында тавыш бирү өчен махсус җиһазландырылган урыннар булырга тиеш. Участокларда тавыш бирүне сораштыру участокларына юнәлдерелгән, Комиссия әгъзаларының берсе җитәкләгән, Комиссия әгъзалары тәэмин итә

6.2. Сораштыруда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган район халкы кертелә. Исемлектә сораштыруда катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса - өстәмә рәвештә көне һәм ае) һәм яшәү урынының адресы күрсәтелә. Сораштыру уздыру буенча тәгаен участокта яшәүчене катнашучылар исемлегенә кертү өчен, аның яшәү урыны шушы участок территориясендә булу факты нигез булып тора. Һәр кеше сораштыруда катнашучылар исемлегенә бары тик сораштыру үткәрү буенча бер генә участокка кертелә. Сораштыруда катнашучылар исемлеге исемлекне төзегән Комиссия рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана.

Әлеге Нигезләмә нигезендә сораштыруда катнашу хокукы булган кешеләр исемлегенә өстәмә кертелү теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сораштыру үткәрелгән көнне дә рөхсәт ителә

Сораштыруда катнашучылар исемлеге, сораштыру үткәрүгә кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча, төзелә.

## 7. Сораштыру кәгазе

7.1. Сораштыру кәгазендә сорау (сораулар) буенча үткәрелгән сорауның төгәл кабатланган тексты була һәм тавыш бирүченең «ӘЙЕ» яки «ЮК» сүзләре белән ихтыяр белдерү вариантлары күрсәтелә, алар астында буш квадратлар урнаштырыла.

7.2. Сораштыруга берничә сорау чыгарылганда, алар бер сораштыру кәгазенә кертелә, эзлекле рәвештә номерлана һәм бер-берсеннән горизонталь сызыклар белән аерыла. Сораштыруга чыгарылган норматив хокукый акт проектының нинди дә булса статьяның яисә нинди дә булса пунктның альтернатив редакцияләре шулай ук эзлекле рәвештә номерлана.

7.3. Сораштыру кәгазендә аны тутыру тәртибе турында аңлатма бирелә Битнең өске уң почмагында Комиссия рәисе һәм секретаре имзалары куела.

## 8. Сораштыруны үткәрү тәртибе

8.1. Сораштыру, гражданнардан сорашып белешүне билгеләү турындагы карарда Район Советы билгеләгән көнгә (яисә көннәрдә), үткәрелә.

8.2. Сораштыру уздыру пунктларында гражданнардан сораштыру иртәнге сигездән алып җирле вакыт белән кичке сәгать 20 гә кадәр гамәлгә ашырыла.

## 9. Сораштыру үткәргәндә яшерен тавыш бирүне үткәрү тәртибе

9.1. Яшерен тавыш бирү, яшерен тавыш бирү урыннары өчен махсус җиһазландырылган һәм тавыш бирү вакытына мөһер сугылган тартмалар урнаштырылган, сораштыру уздыру пунктларында үткәрелә.

9.2. Сораштыру кәгазе сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча тавыш бирүчегә Комиссия әгъзалары тарафыннан бирелә. Сораштыру кәгазен алганда, тавыш бирүче паспортын яисә шәхесен һәм яшәү урынын раслаган башка документны күрсәтә һәм сораштыруда катнашучылар исемлегендә үз фамилиясе турысында имза куя. Сораштыруда катнашучылар исемлегендә паспорт мәгълүматларын тутыру таләп ителми.

9.3. Әгәр тавыш бирүченең сораштыру кәгазен алганда мөстәкыйль рәвештә имза кую мөмкинлеге булмаса, ул, Комиссия әгъзаларыннан тыш, башка зат ярдәменнән файдаланырга хокуклы

Сораштыруда катнашучыга ярдәм итүче зат «Сораштыру кәгазен алу турында сораштыруда катнашучының имзасы» графасында үз фамилиясен күрсәтә.

9.4. Сораштыру кәгазе башка затлар булу рөхсәт ителмәгән махсус

җиһазландырылган урында (кабинада яисә бүлмәләрдә) тутырыла һәм тавыш бирү тартмасына салына.

Тавыш биргәндә сораштыруда катнашучы "ӘЙЕ" яки "ЮК" сүзе астындагы квадратка теләсә кайсы тамганы куя.

9.5. Комиссия әгъзалары сораштыру серен саклыйлар.

Сораштыру кәгазен тутырганда хата ясадым дип санаган кеше, бозылганы урынына яңа сораштыру кәгазе бирүне үтенеп, сораштыру кәгазен биргән Комиссия әгъзасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Комиссия әгъзасы тавыш бирүчегә яңа сораштыру кәгазе бирә, шул ук вакытта сораштыруда катнашучылар исемлегендә әлеге катнашучының фамилиясенә каршы тиешле тамга ясый. Бозылган сораштыру кәгазе юкка чыгарыла, бу хакта Комиссия әгъзалары тиешле акт төзи.

Тутырылган сораштыру кәгазьләре тавыш бирүчеләр тарафыннан Комиссия әгъзалары күз уңында булырга тиешле тартмага төшерелә.

Тартмалар саны Комиссия тарафыннан билгеләнә. Тавыш бирү өчен күчерелмә тартмалар кулланып тавыш бирүне уздыру мәсьәләсен Комиссия мөстәкыйль хәл итә.

9.6. Комиссия әгъзасы сораштыру серен боза яки сораштыруда катнашучыларның ихтыяр белдерүенә йогынты ясарга тырыша икән, ул шунда ук әлеге эштә катнашудан читләштерелә. Читләштерү турында карар әлеге участокта Комиссиянең эшчәнлеген җитәкләүче әгъза тарафыннан тиешле беркетмә төзеп һәм участокта сораштыру уздыручы Комиссиянең барлык әгъзаларының имзалары куелып кабул ителә.

## 10. Сораштыру үткәргәндә ачык тавыш бирүне уздыру тәртибе

10.1. Комиссия, сораштыруда катнашучы халык саны 300 кешедән артмаса, сораштыру үткәргәндә, чыгарылган(чыгарыла торган) сорау (сораулар) буенча тавыш бирүне уздыру өчен сораштыруда катнашучылар җыелышын уздырырга хокуклы. Җыелышта катнашучыларны теркәү сораштыруда катнашучылар исемлеге буенча уздырыла. Җыелышны ким дигәндә өч кеше булган Комиссия вәкилләре ача һәм алып бара. Җыелышта кызыксынучы якларның сораштыруга чыгарылган (чыгарыла торган) мәсьәлә буенча чыгышлары, аларның гражданнарның сорауларына җаваплары рөхсәт ителә, әмма фикер алышу үткәрелми.

10.2. Җыелышта һәр мәсьәлә буенча аерым "ӘЙЕ" һәм аерым "ЮК" тавыш бирү үткәрелә. Тавыш бирүдә исемлеккә кертелгән һәм җыелышта теркәлгән сораштыруда катнашучылар гына катнаша. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул җыелышта катнашучы барлык Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

10.3. Җыелыш сораштыруда катнашучылар исемлегенә кертелгән халыкның 50 проценттан артыгы катнашканда тулы хокуклы була.

## 11. Рәсми сайттан файдаланып сораштыру үткәргәндә тавыш бирүне уздыру тәртибе.

11.1. Әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла торган сораштыруда катнашучыларны ачыклау, гражданнарны рәсми сайттан файдаланып сораштыруда катнашу өчен кирәк

11.2. Сораштыруда катнашучыларны ачыклау рәсми сайтта гамәлгә ашырыла.

11.3. Сораштыруда катнашучыларны ачыклау Бердәм идентификация һәм аутентификация системасын кулланып башкарыла.

Сораштыруда катнашу өчен гражданнарга «Дәүләт хезмәтләре» порталының хисап язмасы ярдәмендә (www.gosuslugi.ru) авторизацияләнергә кирәк.

11.4. Сораштыруда катнашучының «Дәүләт хезмәтләре» порталының хисап язмасы булмаган очракта, граждан «Дәүләт хезмәтләре» порталында (www.esia.gosuslugi.ru Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлә ала.

Рәсми сайт кулланып сораштыру уздырганда күрсәтелгән сайтта «Дәүләт хезмәтләре» порталында Бердәм идентификация һәм аутентификация системасында теркәлү өчен сылтама урнаштырыла.

## 12. Сораштыру нәтиҗәләрен билгеләү

12.1. Сораштыру үткәрелгәннән соң Комиссия сораштыру участоклары буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен саный һәм сораштыру йомгаклары турында карарны сораштыру йомгаклары турында беркетмә белән рәсмиләштерә, анда түбәндәге белешмәләр бирелә:

- беркетмәне төзү датасы;
- сораштыру үткәрү сроклары: башлану һәм тәмамлану даталары;
- сораштыру үткәрү участогы адресы;
-сораштыру территориясе (әгәр сораштыру район территориясе өлешендә үткәрелсә, һичшиксез, урамнарның исемнәре , йортларның номерлары күрсәтелә);
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның (сорауларның) формулировкасы;
- сораштыруда катнашу исемлегенә кертелгән гражданнарның гомуми саны;
- сораштыруда катнашкан гражданнар саны;
- сораштыруны узган яисә узмаган дип тану;
- сораштыру гамәлдә яисә гамәлдә түгел дип тану;
- сораштыру исемлегендә гамәлгә яраксыз дип танылган язмалар саны йә гамәлгә яраксыз дип танылган сораштыру кәгазьләре саны;
- сораштыруда чыгарылган сорауга җавап биргәндә "ӘЙЕ" дип биргән тавышлар саны;
- сораштыруда чыгарылган сорауга җавап биргәндә "ЮК" дип бирелгән тавышлар саны;
-Сораштыру нәтиҗәләре (сорау, аңа җавап биргәндә тавыш бирүдә катнашкан сораштыруда катнашучыларның яртысыннан күбрәге "ӘЙЕ" дип тавыш бирсә, хупланган дип санала).

12.2. Әгәр сораштыру берничә сорау буенча үткәрелгән булса, тавышларны санау һәм беркетмә төзү һәр сорау буенча аерым башкарыла.

12.3. Сораштыру кәгазендәге язмалар түбәндәге очракларда дөрес түгел дип санала:

- сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес билгеләү мөмкин булмаганда;

- язмада тавыш бирүче турында мәгълүмат яисә аның имзасы булмаганда;

кабатлана торган язмалар булганда.

Сораштыру кәгазьләре гамәлгә яраксыз дип танылa:

- билгеләнгән үрнәктәгечә булмаганда,

- Комиссия әгъзаларының билгеләре булмаганда,

- алар буенча сораштыруда катнашучыларның фикерен дөрес билгеләү мөмкин булмаганда.

12.4. Әгәр сораштыруда катнашкан кешеләр саны Район Советы карары белән районда яшәүчеләрнең билгеләнгән сораштыруда катнашачак минималь санынннан кимрәк булса, Комиссия сораштыруны дөрес түгел дип таный.

12.5. Түбәндәге очракларда Комиссия сораштыру нәтиҗәләрен дөрес түгел дип таный:

- сораштыру үткәргәндә җибәрелгән хокук бозулар гражданнарның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәгәндә;

- сораштыру исемлегендә дөрес дип танылган язмалар саны сораштыруда катнашкан гражданнар санының 50%тан кимрәген тәшкил иткәндә;

12.6. Сораштыру нәтиҗәләре турындагы беркетмә 2 нөсхәдә төзелә һәм Комиссиянең барлык әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәгә имза салган вакытта Комиссиянең кайбер әгъзалары булмаган очракта, беркетмәдә аларның булмау сәбәпләрен күрсәтеп, язып куела.

Комиссия әгъзасы беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән ризалашмаса, үз фикерен беркетмәгә кушымта итеп бирелә торган язма рәвешендә бәян итәргә хокуклы, бу хакта беркетмәдә тиешле язма языла. Беркетмә, әгәр ул Район Советы карарында билгеләнгән сораштыру Комиссиясе әгъзаларының күпчелеге тарафыннан имзаланган булса, гамәлдә була.

Беркетмәгә имза салу көне булып Комиссия әгъзалары тарафыннан сораштыру нәтиҗәләрен билгеләгән көн тора.

12.7. Беркетмәнең беренче нөсхәсе Район Советына сораштыру кәгазьләре яисә сораштыру исемлекләре белән бергә җибәрелә, беркетмәнең икенче нөсхәсе сораштыру үткәрү инициаторына җибәрелә.

Беркетмәнең беренче нөсхәсенә Комиссиягә кергән язма шикаятьләр, гаризалар һәм алар буенча кабул ителгән карарлар кушып бирелә. Шикаятьләрнең, гаризаларның һәм алар буенча кабул ителгән карарларның таныкланган күчермәләре беркетмәнең икенче нөсхәсенә кушып бирелә.

Беренче нөсхәнең күчермәләре массакүләм мәгълүмат чараларына, җирле иҗтимагый берләшмәләргә һәм территориаль иҗтимагый үзидарә

органнарына тапшырылырга мөмкин.

12.8. Комиссиясе һәм Район Советы тутырылган сораштыру кәгазьләренең һәм сораштыру исемлекләренең сакланышын һәм кагылгысызлыгын тәэмин итәләр.

## 13. Сораштыру нәтиҗәләре

13.1. Сораштыру нәтиҗәләре, аларны билгеләгән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

13.2. Сораштыру барышында ачыкланган халык фикере тәкъдим итү характерына ия. Сораштыру нәтиҗәләре җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарәсенең вазыйфаи затлары, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары карарлар кабул иткәндә һичшиксез каралырга һәм исәпкә алынырга тиеш.

13.3. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары сораштыру нәтиҗәләренә каршы килә торган карарлар кабул иткән очракта, күрсәтелгән органнар тиешле карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә тиешле мәгълүматны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юлы белән шундый карар кабул итү сәбәпләрен халыкка җиткерергә тиеш.

## 14. Сораштыру материалларын саклау

14.1. Сораштыру материаллары Район Советы аппаратында саклана.

14.2. Сораштыру материалларын саклау срогы- 1 ел

## 15. Сораштыру үткәрүне финанс белән тәэмин итү

15.1. Гражданнарны сораштыру әзерләүгә һәм үткәрүгә бәйле чараларны финанслау түбәндәге акчалар хисабына гамәлгә ашырыла:

- җирле үзидарә органнары яки муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча сораштыру уздырганда -җирле бюджет;
- Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы белән сораштыру уздырганда - Татарстан Республикасы бюджеты.

## 16. Сораштыруда катнашуга гражданнарның хокукларын бозган өчен җаваплылык

16.1. Көч куллану, сатып алу, янау, документлар ясау юлы белән яисә Россия Федерациясе гражданы тарафыннан сораштыруда катнашу хокукын иректе гамәлгә ашыруга комачаулый торган башка ысул белән яисә комиссия эшенә яки комиссия әгъзалары эшенә каршылык тудырган затлар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылык тоталар.